**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от 23.11.2020** **№ 885**

**2021 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 14 декабрендәге 854 нче номерлы «Татарстан Республикасы балаларга сәнгать-эстетик юнәлешендәге өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» карары һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елга расларга:

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга сәнгать-эстетик юнәлешендәге өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарын кушымта нигезендә;

балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата 0,5 күләмендә төзәтмәләр коэффициентын.

2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә тарала.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

Кушымта

РАСЛАНГАН

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең 2020 елның 23 ноябренең 885 нче номерлы карары белән

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга сәнгать-эстетик юнәлешендәге өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә**

**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокациясе | Норматив чыгымнар (1 укучыга елга сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык укыту срогы | дүрт еллык укыту срогы | биш еллык укыту срогы | җиде еллык укыту срогы | иртә һөнәри ориентация |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | | | 60 519 | 70 105 | 90 982 |
| Рәсем сәнгате | авыл җирлеге | | 33 235 | | 28 980 | 69 559 |
| Хореографик сәнгать | авыл җирлеге | | | 63 795 | 52 609 | 191 884 |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 27 818 | | |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 60 079 | 57 660 | 93 239 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 92 265 | | 88 340 | | 145 742 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 47 585 | | 44 206 | 44 213 | 69 610 |